СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с. Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республика Арча муниципаль районы**
**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«22» сентябрь 2020 ел** **№6**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 15.05.2019 ел, №104«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы кодексы, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләүләре күләмен арттыру турында" карары, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 15.05.2019ел, №104 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәнең 3 абзацын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәте өчен түләү *акчалата түләү рәвешендә башкарыла.*

| Вазыйфа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы | 17253 |

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында Нигезләмәнең 12 абзацында (2 нче кушымта) "11 163 сум" сүзләрен "11 498 сум" сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге баш бухгалтерының хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмәнең 3 абзацын (4 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Баш бухгалтерның вазыйфаи окладды түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Башкарма комитетның комитеты муниципаль берәмлекләрендә халык саны |
|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр |
| Баш хисапчы | 16 171сум |

4) Түбәндәге эчтәлекле 8 нче кушымта өстәргә:

Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә.

2.Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында “Авыл җирлекләре “ бүлегендә урнаштырыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Иске Кырлай авыл җирлегенең
22.09.2020 ел, №6 карарына 8
*нче кушымта*

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча айлык акчалата бүләкләүдән, айлык акчалата бүләктән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск вакытында бер тапкыр бирелә торган түләү, матди ярдәм, шулай ук закон нигезендә каралган башка түләүләрдән гыйбарәт. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштергән өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәүче хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәгән өчен өстәмә түләүләр кертелә;

белгечләрнең вазыйфаи окладлары күләме 11 498,0 сум тәшкил иткән вазыйфаи окладны тапкырлап исәпләнә. Тапкырлау коэффициентлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа атамасы | Коэффициент |
|---|---|
| | V төркем |
| Баш белгеч | 1,1 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,05 |
| I категорияле белгеч | 1,00 |
| II категорияле белгеч | 1,00 |
| Белгеч | 1,00 |

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге белгечләренә билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә түләү, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10елдан 15 елга | 10 |
| 15 елдан күбрәк | 15; |

2) вазыйфа окладының 10 проценты күләмендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата түләү;

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) түләүле еллык ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр белгечкә календарь ел дәвамында түләнә торган еллык ял бирелмәсә, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа декабрь аенда эшләнгән вакытка пропорциональ

рәвештә түләнә, эштән азат ителгән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Бер тапкыр бирелә торган түләү, түләүле еллык ял биргәндә, белгечкә эшнең беренче елында пропорциональ рәвештә календарь елда башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә кадәр эшкә кергән көннән исәпләнә;

6) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә матди ярдәм.

2. Хезмәткәрләргә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарырга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге белгечләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчалардан тыш, түбәндәге акчалар карала (бер елга 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладларның җиде проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә-вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр-вазыйфаи окладларның бер проценты күләмендә;

4) вазыйфаи окладларның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;;

5) вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә еллык түләүле отпуск һәм матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге белгечләренә, шулай ук эшчеләргә айлык һәм башка түләүләр күләмнәре сумнарга кадәр арттырып түгәрәкләнә дип билгеләргә.